ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КРАСНОСЕЛЬСКИЙ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422700, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Биектау тимер юл станциясе поселогы, Совет ур., 13

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КРАСНОСЕЛЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422700, Республика Татарстан, Высокогорский район,
п. ж/д ст. Высокая Гора, ул. Советская, 13

тел./факс 8(84365) 2-35-82, e-mail: Ksel.Vsg@tatar.ru

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**1 февраль 2024 ел** **№ 2**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлегендә җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында**

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы «Җирләү һәм күмү эше турында» Федераль закон, 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында», 2024 елның 23 гыйнварындагы 46 нчы номерлы «2024 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләр индексациясе коэффициентын раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең карары нигезендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. 2024 елның 1 февраленнән Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлегендә җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 8370 сум 20 тиен күләмендә 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. 2021 елның 15 апрелендәге Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Башкарма комитеты «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлегендә җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында» карарын 2024 елның 1 февраленнән үз көчен югалткан дип танырга

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталының рәсми сайтында: http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Биектау муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында: http//vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Красносельский авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе Р.Ф. Нуруллин

2024 нче елның 1 февралендәге Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Башкарма комитеты 2 нче номерлы карарына

1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлегендә җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясе

| Хезмәтләр исеме | Хезмәтләрнең бәясе (сум) |
|---|---|
| 1. Мәет күмү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Мәет җирләү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 5542,3 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка китерү | 669,31 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2158,59 |
| Барлыгы | 8370,2 |

2024 нче елның 1 февралендәге Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Башкарма комитеты 2 нче номерлы карарына
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлегендә җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясе

| Хезмәтләр исеме | Хезмәтләрнең бәясе (сум) |
|---|---|
| 1. Мәет күмү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Кәфенләү | 301,18 |
| 3. Мәет җирләү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 5241,12 |
| 4. Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка китерү | 669,31 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2158,59 |
| Барлыгы | 8370,2 |